| Республика Татарстан<br>Кавзияковское сельское<br>поселение Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Кәүҗияк<br>авыл җирлеге |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 7 май № 9

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын уздыру өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" урнаштырырга .PRAVO.TATARSTAN.RU( Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең рәсми сайтында "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Н. Әхмәтгараевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман районы Кәүҗияк
авыл җирлеге Советы Рәисе. Ф.Н.Әхмәтгараев